РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ КУКМОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

19.08.2026 Кукмара ш. № 448

Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2021 елның 18 августындагы 536 номерлы карары белән расланган Кукмара муниципаль районында гражданнар оборонасы буенча чараларны тәэмин итү турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2026 елның 19 гыйнварындагы 7 номерлы карары нигезендә **карар бирәм:**

Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2021 елның 18 августындагы 536 номерлы карары белән расланган Кукмара муниципаль районында гражданнар оборонасы буенча чараларны тәэмин итү турындагы нигезләмәгә, (Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2023 елның 14 августындагы 452 номерлы, 2025 елның 01 декабрендәге 668 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып), түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) преамбулада «Татарстан Республикасында гражданнар оборонасы буенча чараларны тәэмин итү һәм коткару хезмәтләрен булдыру турында» 2010 елның 15 гыйнварындагы 6 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары» (ТР Министрлар Кабинетының 2011 елның 18 октябрендәге 862 номерлы, 2012 елның 27 апрелендәге 331 номерлы, 2013 27 апрелендәге 287 номерлы, 2014 елның 06 октябрендәге 716 номерлы, 2016 елның 04 февралендәге 66 номерлы, 2018 елның 12 февралендәге 74 номерлы карарлары редакциясендә) сүзләрен төшереп калдырырга;

2) 5 нче пунктның беренче абзацында «хәрби каршылыклар булганда яисә шушы конфликтлар аркасында, шулай ук табигый һәм техноген характердагы

гадәттән тыш хәлләр вакытында» сүзләрен «мобилизация чорында, хәрби хәл гамәлдә булган чорда, сугыш чорында» сүзләренә алмаштырырга;

3) 6 нчы пунктта:

беренче абзацта «имин районнарга матди һәм мәдәни кыйммәтләрне» сүзләрен «матди һәм мәдәни кыйммәтләрне яклау» сүзләренә алмаштырырга;

икенче абзацта «эвакуацияне планлаштыруны, әзерләүне һәм уздыруны оештыру» сүзләрен «халыкны эвакуацияләүне планлаштыруны, әзерләүне һәм уздыруны, матди һәм мәдәни кыйммәтләрне яклауны оештыру.» сүзләренә алмаштырырга

3) 9 нчы пунктта:

беренче абзацта «хәрби каршылыклар вакытында яисә шушы каршылыклар нәтиҗәсендә, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр вакытында халык өчен куркынычлар барлыкка килү» сүзләрен ««мобилизация чорында, хәрби хәл гамәлдә булган чорда, сугыш чорында барлыкка килә торган куркынычлар» сүзләренә алмаштырырга;

2 абзацта «оборона һәм» сүзләрен «оборона, җиһазлау һәм кирәкле көчләрне әзерләү» сүзләренә алмаштырырга;

4) 10 нчы пунктта:

беренче абзацта «хәрби каршылыклар булганда яисә шушы каршылыклар аркасында, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр вакытында» сүзләрен «мобилизация чорында, хәрби хәл гамәлдә булган чорда, сугыш чорында килеп чыга торган куркынычлар нәтиҗәсендә» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацны үз көчен югалткан, дип танырга;

алтынчы абзацта «хәрби каршылыклар вакытында яисә шушы каршылыклар нәтиҗәсендә» сүзләрен «мобилизация чорында, хәрби хәл гамәлдә булган чорда, сугыш чорында килеп чыга торган куркынычлар нәтиҗәсендә» сүзләренә алмаштырырга;

5) 11 нче пунктта:

беренче абзацта «хәрби каршылыклар вакытында яисә шушы каршылыклар нәтиҗәсендә барлыкка килгән» сүзләрен «мобилизация чорында, хәрби хәл гамәлдә булган чорда, сугыш чорында килеп чыга торган куркынычлар нәтиҗәсендә булган» сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзацта «сугыш чорында» сүзләрен төшереп калдырырга;

дүртенче абзацта «сугыш чорында» сүзләрен төшереп калдырырга;

6) 12 нче пунктның беренче абзацында «хәрби каршылыклар булганда яисә шушы каршылыклар аркасында, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр вакытында» сүзләрен «мобилизация чорында, хәрби хәл гамәлдә булган чорда, сугыш чорында килеп чыга торган куркынычлар нәтиҗәсендә» сүзләренә алмаштырырга;

7) 15 нче пунктта:

беренче абзацта «хәрби каршылыклар яисә шушы каршылыклар аркасында, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр вакытында» сүзләрен «мобилизация чорында, хәрби хәл гамәлдә булган чорда, сугыш чорында килеп чыга торган куркынычлар» сүзләренә алмаштырырга;

икенче һәм бишенче абзацларда «тыныч вакытта һәм сугыш чорында» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында (http://kukmor.tatarstan.ru) урнаштырырга.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **А.Х. Гарифуллин**